**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Микулино авыл җирлеге Советы карары**

Микулино авылы №170 «19» 05.2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының 2020 елның 02 мартыннан 161 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлегенең бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлегенең бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2020 елның 06 майнын 167 номерлы карар редакциясендә)

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлегенең бюджет процессы нигезләмәләрен Россия Федерациясенең гамәлдәге бюджет законнарына туры китерү максатыннан,

Микулино авыл җирлеге Советы карра итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының 2020 елның 02 мартыннаен 161 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлегенең бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлегенең бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә (2020 елның 06 майнын номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 9 статьяда:

а) 7 пунктны түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча белән тулыландырырга:

«3) федераль закон нигезендә тиешле гавами-хокукый берәмлек мәнфәгатьләрен Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә муниципаль берәмлек бюджеты акчаларын баш бүлүченең вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы орган тәкъдим итә торган муниципаль берәмлеккә карата бүтән дәгъвалар буенча);»;

б) 12 пунктны түбәндәге эчтәлекле җиденче, сигезенче абзацлар белән белән тулыландырырга:

«-Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән мондый методикага карата гомуми таләпләр нигезендә бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча керемнәрне фаразлау методикасын раслый;

- бюджет ассигнованиеләренең нигезләнешен тәшкил итә.».

1.2. 14 статьяны яңа редакциядә бәян итәргә:

«14 статья. Муниципаль заказ

1. Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу җирле бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.».

1.3. 34 статьяның 2 пунктын түбәндәге эчтәлекле җиденче абзац белән тулыландырырга:

«-озак вакытлы чорга бюджет фаразы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразына үзгәрешләр кертү проекты).».

1.4. 40 статьяның 2 пунктындагы өч абзацында «ике» сүзен «өч» сүзенә алмаштырырга.

1.5. 49 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Бюджетның бердәм счетында калдыклар белән идарә итү операцияләреннән тыш, җыелма бюджет язмасына бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча бюджет ассигнованиеләре кертелә.».

1.6. 50 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бюджет йөкләмәләре чыгымнары һәм лимитлары буенча бюджет язмасы күрсәткечләре, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 190 һәм 191 статьяларында каралган очраклардан тыш, чираттагы финанс елы башына кадәр ведомство буйсынуында булган бюджет акчаларын алучылар һәм бүлүчеләргә җиткерелә.».

1.7. 52 статьяның дүртенче абзацында «салымнар һәм җыемнар турында» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.8. 53 статьяның 2 пунктындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бюджет һәм акчалата йөкләмәләрне кабул итү һәм исәпкә алу.».

1.9. 53 статьяның 4 пунктындагы беренче абзацны үз көчен югалткан дип танырга.

1.10. 56 статьяның 2 пунктындагы өченче абзацында «бюджет учреждениесенең» сүзләрен «казна учреждениесенең» сүзләренә алмаштырырга.

2. . Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Азнакай районы Микулино авыл җирлеге Советының бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис И.А.Такиулин